Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районының "Иске Алпар авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге
Советы карары белән кабул ителде
2025 елның «08» августы № 121

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы**
**«Иске Алпар авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге Уставына Үзгәрешләр**
**һәм өстәмәләр кертү турында**

Иске Алпар ав.

| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әлки муниципаль районы**<br>**Иске Алпар авыл җирлеге**<br>**Советы** | | **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**Совет Староалпаровского**<br>**сельского поселения**<br>**Алькеевского муниципального**<br>**района** |


422877, ТР, Иске Алпар авылы,
Тоньяк урамы, 29 й.
Тел: (84346) 72553

422877, РТ, Алькеевский район,
с. Старое Алпарово, ул.Северная,
д.29
тел: (84346) 72553


РЕШЕНИЕ Иске Алпар ав. КАРАР

2025 елның " 08 " августы № 121

Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге Советының 23.10.2023 елның 78-нче номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Иске Алпар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында " карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы Прокуратурасының хокук булдыру инициативасын өйрәнеп, муниципаль берәмлек Уставының 85,86 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Алпар авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Алпар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 23.10.2023 елның 78-нче карары белән (29.07.2024 елның 98-нче карары редакциясендә) 1 нче кушымта нигезендә расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Алпар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Алпар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Алпар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Алпар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы статьяларының яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Иске Алпар авыл җирлеге территориясендә: Татарстан Республикасы, Әлки районы, Иске Алпар авылы, Төньяк ур., 29 (җирле үзидарә бинасы), Иске Алпар авылы , Төньяк ур., 29 йорт (авыл мәдәният йорты) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында (http://alkeevskiy.tatarstan.ru.) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
«Иске Алпар авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Советы Рәисе Р.Р.Сәлахов

СОВЕТ СТАРОАЛПАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ОГРН 1021605756809 ИНН 1606000868 КПП 160601001

1 нче кушымта
Әлки муниципаль районы
Иске Алпар авыл җирлеге
Советы карарына
08.08.2025 ел, № 121

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Иске Алпар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 19.1 пункт өстәргә:
"19.1" шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112 номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып барган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру".